РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин ур.,14 нче йорт, Азнакай ш., 423330

Тел. /факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar. ru, adm-aznakay@mail. ru; http://aznakayevo. tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.03.2023 ел № 08

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 26 июлендәге 86-17 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2023 елның 02 мартындагы Азнакайда җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 26 июлендәге 86-17 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә:

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай ш. адресы буенча урнашкан 16:44:0166:560 кадастр номеры булган 3600,0 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген ндивидуаль торак төзелешенең территориаль зонасы (Ж1) чикләрен планлаштырыла торган территориядән файдалануга туры килә торган итеп билгеләргә.

2. Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә. (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.А. Габдрахманов

Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре башкарма комитетының карарына 1 нче кушымта

____________________ 2023 ел №_____

**Азнакай муниципаль районы “Азнакай шәһәре” муниципаль берәмлек җирләреннән файдалану һәм төзелеш эшләре кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү һәм әзерләү эшләрен үткәрү тәртибе һәм вакытлары**

| N | Азнакай муниципаль районы "Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Азнакайда җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен оештыру. | 2023елның I кварталы. |
| 2.<br>2.1.<br>2.2. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү һәм килештерү.<br>Җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә һәм картографик материалларга үзгәрешләр кертү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә шәрехләр әзерләү. | 2023елның I-II кварталлары. |
| 3.<br>3.1.<br>3.2.<br>3.3.<br>3.4. | Азнакай шәһәрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты турында фикер алышу.<br>Гавами тыңлаулар үткәрү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектына үзгәрешләр кертү.<br>Күрсәтелгән проектны һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) башкарма комитет җитәкчесенә тапшыру.<br>Күрсәтелгән проектны һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) Башкарма комитет җитәкчесенә тапшыру. Азнакай муниципаль районы башлыгына әлеге проектны шәһәр Советына раслауга яки кире кагуга кертү һәм аны кабат тапшыру вакытын күрсәтеп, эшләп бетерергә җибәрү турында карар кабул итү өчен Азнакай шәһәренең Җир биләмәләреннән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект җибәрү. | 2023елның I-II кварталлары. |